**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре | № 188-34 | «29» август 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26, 12.11.2018 №114-28, 13.12.2018 №119-29, 23.05.2019 №138-33, 26.11.2019 №153-37, 26.02.2021 №26-6 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- түбәндәге эчтәлекле 2 пунктны өстәргә:

«6) гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган сәүдә һәм административ эшлекле үзәкләргә (комплексларга) карата һәм Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгы боерыгы белән расланган Исемлеккә кертелгән биналарга карата 1,2 процент;».

2. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин